Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы Шигали авыл җирлеге

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Шигали авыл җирлеге Яңа Шигали авылының Груша, Алмагач, Бәхетле, Чияле, Земляничная, Җиләкле, Миләш, Бакча, Чикләвек, Слива урамнары гражданнар җыены нәтиҗәләре турында
**КАРАР**

6 ноябрь, 2022 ел № 2

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Шигали авыл җирлегенең Яңа Шигали авылының Груша, Алмагач, Бәхетле, Чияле, Земляничная, Җиләкле, Миләш, Бакча, Чикләвек, Слива урамнарында яшәүчеләрнең 2022 елның 6 ноябрендәге гражданнар җыены беркетмәсе нигезендә авыл җирлегендә яшәүчеләр белән очрашу беркетмәсе нигезендә:

- җыенны уздыру өчен билгеләнгән территориядә яшәүче һәм халык җыенында катнашырга хокуклы гражданнар саны 82 (сиксән ике).
- халык җыены эшендә катнашкан гражданнар саны 43 (кырык өч).
- гражданнар җыенына кертелгән мәсьәләгә «**РИЗА**» өчен гомуми сан 43 (кырык өч).
- гражданнар җыенына кертелгән мәсьәләгә «**КАРШЫ**» өчен гомуми сан 0 (ноль).

Югарыда бәян ителгәннәрдән чыгып түбәндәге карар кабул ителде:

1. «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» гы 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25 статьясындагы 6 өлеше нигезендә **гражданнар җыены мәсьәләсе буенча карарын**, түбәндәге мәсьәлә буенча «Сез, 2023 елда Яңа Шигали авылының Груша, Алмагач, Бәхетле, Чияле, Земляничная, Җиләкле, Миләш, Бакча, Чикләвек, Слива урамнары территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, махсус хәрби операциядә катнашучыларны һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш һәр балигъ булган кешедән 3000 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны алдагы эшләрне башкару өчен куллану белән килешәсезме?:

- балалар мәйданчыгы төзелеше»

**кабул ителгән дип санарга.**

2. Әлеге карарны «Вперёд» («Алга») газетасында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru), Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) һәм Шигали авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында да бастырып чыгарырга (халыкка игълан итәргә).

Шигали авыл җирлеге башлыгы В.М. Сәлимов